Республика Татарстан
Совет Новоимянского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Яңа Имән авыл җирлеге
советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**01 март 2019 ел** **№ 4**

**Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварындагы 17 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы “Яңа Имән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы һәм Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Имән авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварындагы 17нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Яңа Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) нигезләмәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын куллану турында нигезләмә

2) "Үзара салым акчаларын җыю тәртибе"турындагы 5 нче кисәкне гамәлдән чыгарырга һәм муниципаль берәмлекнең аерым норматив хокукый акты белән билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Имән авыл җирлеге Советы рәисе *Гараев* Р.Ф.Гараев.